## Апрель аенда кояш чыгу, кояш бату һәм намаз уку вакытлары

| Көннәр | Иртәнге намаз | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Кояш бата Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 4.44 | 6.14 | 13.05 | 17.09 | 19.17 | 20.47 |
| 2 | 4.41 | 6.11 | 13.05 | 17.11 | 19.19 | 20.49 |
| 3 | 4.39 | 6.09 | 13.05 | 17.12 | 19.20 | 20.50 |
| 4 | 4.37 | 6.07 | 13.05 | 17.13 | 19.22 | 20.52 |
| 5 | 4.34 | 6.04 | 13.05 | 17.14 | 19.24 | 20.54 |
| 6 | 4.32 | 6.02 | 13.05 | 17.16 | 19.26 | 20.56 |
| 7 | 4.29 | 5.59 | 13.05 | 17.17 | 19.28 | 20.58 |
| 8 | 4.27 | 5.57 | 13.05 | 17.18 | 19.29 | 20.59 |
| 9 | 4.25 | 5.55 | 13.05 | 17.20 | 19.31 | 21.01 |
| 10 | 4.22 | 5.52 | 13.05 | 17.21 | 19.33 | 21.03 |
| 11 | 4.20 | 5.50 | 13.05 | 17.22 | 19.35 | 21.05 |
| 12 | 4.18 | 5.48 | 13.05 | 17.23 | 19.37 | 21.07 |
| 13 | 4.15 | 5.45 | 13.05 | 17.25 | 19.38 | 21.08 |
| 14 | 4.13 | 5.43 | 13.05 | 17.26 | 19.40 | 21.10 |
| 15 | 4.11 | 5.41 | 13.05 | 17.27 | 19.42 | 21.12 |
| 16 | 4.09 | 5.39 | 13.05 | 17.28 | 19.44 | 21.14 |
| 17 | 4.06 | 5.36 | 13.05 | 17.29 | 19.46 | 21.16 |
| 18 | 4.04 | 5.34 | 13.05 | 17.31 | 19.47 | 21.17 |
| 19 | 4.02 | 5.32 | 13.05 | 17.32 | 19.49 | 21.19 |
| 20 | 4.00 | 5.30 | 13.05 | 17.33 | 19.51 | 21.21 |
| 21 | 3.57 | 5.27 | 13.05 | 17.34 | 19.53 | 21.23 |
| 22 | 3.55 | 5.25 | 13.05 | 17.35 | 19.55 | 21.25 |
| 23 | 3.53 | 5.23 | 13.05 | 17.36 | 19.56 | 21.26 |
| 24 | 3.51 | 5.21 | 13.05 | 17.38 | 19.58 | 21.28 |
| 25 | 3.49 | 5.19 | 13.05 | 17.39 | 20.00 | 21.30 |
| 26 | 3.46 | 5.16 | 13.05 | 17.40 | 20.02 | 21.32 |
| 27 | 3.44 | 5.14 | 13.05 | 17.41 | 20.04 | 21.34 |
| 28 | 3.42 | 5.12 | 13.05 | 17.42 | 20.05 | 21.35 |
| 29 | 3.40 | 5.10 | 13.05 | 17.43 | 20.07 | 21.37 |
| 30 | 3.38 | 5.08 | 13.05 | 17.44 | 20.09 | 21.39 |

*Намаз вакытлары турында мәгълүматларны Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте хезмәткәрләре өзерләде, мөфти Вагыйз хәзрәт ЯРУЛЛИН раслады. Җомга көннәре аерып күрсәтелгән.*

**Учредители: трудовой коллектив редакции газеты «Бердэмлек» и Региональное Духовное управление мусульман Самарской области.**

**Оештыручылар: «Бердәмлек» газетасы редакциясенең хезмәт коллективы һәм Самара өлкәсе мөселманнарының Региональ Диния нәзарәте.**

بِسْمِ اللّٰهِ الرَّحْمٰنِ الرَّحِيمِ

# Кыйбла

„БЕРДЭМЛЕК" ГАЗЕТАСЫНЫҢ АЙЛЫК ДИНИ КУШЫМТАСЫ

№ 3
2012 ел
март



*ВӘГАЗЬ*

# Яралтылу һәм кешенең җаваплылыгы

Яралту бер әйберне юктан бар итү дигән сүз. Галәмдә күзгә күренгән яисә күренмәгән һәрнәрсәне юктан бар итеп яралтучы Аллаһыдыр. Аллаһының тиңе юктыр. Аятьләрдә «Ул күкләрне һәм җирне юктан яралтты, бар итте» гыйбарәсе бик еш телгә алына. Шул ук вакытта бар нәрсәне билгеле бер тәртип һәм гармония эчендә яралтуы белән бәйле гыйбарәләр дә киң урын ала. Бар әйберне билгеле бер гармония эчендә яралтучы Аллаһы кешене дә иң матур шәкелдә барлыкка китерә. Кешене төрле этаплар аша уздырып, аны үз рухыннан өреп яралта. Аллаһы яралткан һәрнәрсә кешенең хезмәтенә тәкъдим ителә. Аллаһы фәрештәләрдән кешегә сәҗдә итүләрен сораганда аның никадәр кыйммәтле барлык булуына басым ясый. Зур тырышлык һәм ихласлык белән барлыкка китерелгән кешенең бу кыйммәткә күрә яшәве үз җаваплылыгында. Кеше бу җаваплылыкны җиренә җиткермәвенә күрә ахирәттә җавап бирәчәк.

Кеше Аллаһы хакында ничек фикер йөртсә, Аллаһы да аның белән шул рәвешле бәйләнеш кора. Шуңа күрә Мөхәммәд Пәйгамбәргә болай дип әйтә: *«Колым минем хакымда нәрсә уйласа, мин дә шулай ук фикер йөртәм. Ул мине хәтерләсә, мин дә аның янында булырмын. Ул миңа бер карыш якынайса, мин аңа бер аршын якынлашырмын. Ул миңа бер аршын якынайса, мин аңа бер колач якынлашырмын. Колым миңа атлап килсә, мин аның янына йөгереп барырмын».*

Аллаһы кешене үзенә гыйбадәт итсен дип яралта. Аллаһыга гыйбадәт кылу - аның барлыгын һәм берлеген кабул итеп, аның әмер һәм тыюларын үтәп яшәргә тырышу дигән сүз. Кеше Аллаһыны күбрәк дога юлы белән исендә тота. Дога — Аллаһы белән кеше арасында үзенчәлекле элемтә, бәйләнеш кору рәвеше ул. Аллаһы дога кылып үзенә якынайган колларын аеруча үз итә, ярата. Кеше дога кылганда Аллаһы белән хис-тойгыларын һәм уй-фикерләрен уртаклаша. Берәүгә дә аңлата алмаган серләрен дә Аллаһыга аңлатып, аның белән бүлешә. Дога - Аллаһының бөеклеген кабул итү дигән сүз. Кеше бары тик үзе өчен генә түгел, башкалар өчен дә дога итә. Бу исә кешеләрнең бер-берсенә якынлашуларына сәбәп була. Ислам традициясендә кешеләрнең үзләреннән бигрәк бер-берсе өчен дога иткән вакытта, бу догаларның кабул булуы тәгълиматы яшәп килә.

Кешенең Аллаһыны исендә тоту, аны хәтерләүнең тагын бер юлы - яхшы эшләр, изге гамәлләр башкаруы. Ислам традициясендә моңа салих гамәл дип әйтәләр, ягъни Аллаһының ризалыгын казану максаты белән башкарылган файдалы һәм әйбәт эшләр. Эшләнгән һәр яхшылык, елмаюлы йөз, юлын югалтучыларга дөрес юл күрсәтү - барысы да яхшы, изге гамәлләр. Кеше нигә төрле юллар белән Аллаһыга якынаерга һәм аны исендә тотарга тиеш соң? Чөнки Аллаһы аны яралтты, фәкать аны ирекле калдырды. Аллаһы үзе биргән барлык нигъмәтләр белән кешеләрне сыный. Адәм баласы бу сынауны үзе теләп кабул итә. Аятьтә: *«Без әманәтне күкләргә, җир һәм тауларга юнәлттек. Алар аны үз өсләренә алмадылар, аның җаваплылыгыннан курыктылар. Бу җаваплылыкны кеше үз өстенә алды»,* - диелә. Аллаһы кешене үз-үзенә һәм җир йөзендә аның өчен барлыкка китергән һәрнәрсәне аңа әманәт итеп тапшыра. Кешенең сынавы - бу әманәтне саклау. Кеше моны тормышка ашырганда гадел булырга, хаксызлыктан ерак торырга тиеш. Шәфкатьле һәм мәрхәмәтле булырга, һәрнәрсәгә сөю белән якынаерга, юмарт булырга тиеш.

Кешенең Аллаһы биргән нигъмәтләрне бүлешүдә юмарт булуы зарур. Гафу итә белергә, үзенең һәм башка кешеләрнең хаталарына карата түземле һәм яхшы мөгамәләдә булырга, бу хаталар кабатланмасын өчен форсат бирергә тиеш. Бу сыйфатлар - Аллаһының сыйфатлары. Ул ярата, ул мәрхәмәтле, гадел, юмарт һәм гафу итә белүче. Ул җир йөзендә үзен вәкиллек үтүче хәлифәсе булган кешедән бу сыйфатларга ия булу өчен ярышуларын тели. Имтихан мәсьәләсе нәкъ менә будыр.